СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

27.02.2018 | с. Нижний Услон | 40-160

Түбән Ослан авыл җирлеге Советының «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымын түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 29.09.2017 ел, № 35-136 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Югары Ослан районы прокурорының 09.01.2018 ел № 02-07-02 протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1.Түбән Ослан авыл җирлеге Советының «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымын түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 29.09.2017 ел, № 35-136 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата бирелә, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган ташламалар салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы өчен генә бирелә»;

1.2. Әлеге карарның 3 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым түләүчеләр-әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән физик затлар салым органына үз теләкләре белән салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы. А.З. Шайдуллин